МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

26.03.2019 г.Казань № 186-осн

Татарстан Республикасы Урман
хуҗалыгы министрлыгының
ведомство бүләкләре турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, урман хуҗалыгы өлкәсендә эшләүче затларны, шулай ук тармакны үстерүдә һәм популярлаштыруда актив катнашучы башка затларны кызыксындыру һәм кызыксындыру системасын камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының түбәндәге ведомство бүләкләрен гамәлгә куярга:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Мактау грамотасы;

Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры Рәхмәте.

2. Кушымтада бирелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Мактау грамотасы турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры Рәхмәте турында нигезләмә:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибе.

3. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының ведомство бүләкләре турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 554-осн номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Министр Р.Ә. Кузюров

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 26 мартындагы 186-осн номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының

Мактау грамотасы турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Мактау грамотасы (алга таба – Мактау грамотасы, Министрлык) Министрлыкның ведомство бүләге булып тора.

2. Мактау грамотасы белән Министрлыкның һәм аңа буйсынган дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка башкарма органнары, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә урман хуҗалыгын гамәлгә ашыруда һәм үстерүдә зур өлеш керткән оешмаларның, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, иҗтимагый берләшмәләрнең коллективлары һәм хезмәткәрләре, хезмәт эшчәнлегендәге югары казанышлары, дәүләти, һөнәри бәйрәмнәргә, вакыйгалы һәм персональ юбилей даталарына бәйле рәвештә, бүләкләнә.

3. Мактау грамотасы белән Министрлыкның һәм аның ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләренең тармакта кимендә 5 еллык эш стажына ия булган һәм элегрәк Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры Рәхмәте белән билгеләп үтелгән хезмәткәрләре бүләкләнә.

4. Мактау грамотасы белән бүләкләү әлеге боерык белән расланган Министрлыкның ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Мактау грамотасын тапшыру тантаналы шартларда башкарыла. Мактау грамотасының дубликаты бирелми. Мактау грамотасын югалткан очракта, Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре секторыннан Министрлыкның герблы мөһере белән расланган бүләкләү турындагы боерыктан өземтә бирелә.

6. Мактау грамотасы белән бүләкләнгән Министрлык хезмәткәрләренә Министрлыкның хезмәткә түләү фонды акчалары хисабына вазыйфаи окладның 25 проценты күләмендә бер тапкыр акчалата бүләк түләнә.

Мактау грамотасы белән бүләкләнгән Министрлык карамагындагы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә дәүләт учреждениесенең хезмәткә түләү фонды акчалары хисабына бер тапкыр акчалата бүләк түләнә.

7. Мактау грамотасы белән бүләкләнгән затларны исәпкә алуны Министрлык башкара.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 26 мартындагы 186-осн номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры

Рәхмәте турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры Рәхмәте (алга таба – Рәхмәт) Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының ведомство бүләге (алга таба – Министрлык) булып тора.

2. Рәхмәт белән Министрлыкның һәм аның ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре, шулай ук тармак үсешенә зур өлеш керткән оешмаларның, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, иҗтимагый берләшмәләрнең коллективлары һәм хезмәткәрләре аеруча әһәмиятле һәм катлаулы йөкләмәләрне үтәгән өчен, нәтиҗәле һәм намуслы дәүләт граждан хезмәте өчен, дәүләти, һөнәри бәйрәмнәргә, истәлекле һәм персональ даталарга бәйле рәвештә бүләкләнә.

3. Рәхмәт белән Министрлыкның һәм аның ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләренең тармакта кимендә 1 еллык эш стажына ия булган хезмәткәрләре бүләкләнә.

4. Рәхмәт белән бүләкләү әлеге боерык белән расланган Министрлыкның ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Рәхмәт тапшыру тантаналы шартларда башкарыла. Рәхмәтнең дубликаты бирелми. Рәхмәтне югалткан очракта, Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре секторыннан Министрлыкның герблы мөһере белән расланган бүләкләү турындагы боерыктан өземтә бирелә.

6. Министрлык Рәхмәт белән бүләкләнгән затларны исәпкә алуны башкара.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 26 мартындагы 186-осн номерлы боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының (алга таба – Министрлык) ведомство бүләкләре бүләкләү формасы булып тора һәм Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

2. Бүләкләү башкарыла:

бер елдагы эшкә йомгак ясаганда;

оешмаларның һөнәри бәйрәмнәрен, истәлекле һәм юбилей даталарын бәйрәм иткәндә.

Бүләкләү гражданнарның юбилей даталарына (50, 55, 60, 65 яшь һәм аннан соңгы һәр 5 еллык туган көн), оешмаларның (учреждениеләрнең, берләшмәләрнең) юбилей даталарына (10 ел, 20 ел һәм оешкан елыннан соңгы һәр 10 ел саен) туры китерелергә мөмкин.

3. Урман хезмәткәре көнен (сентябрь аеның өченче якшәмбесе) бәйрәм итүгә багышланган ведомство бүләкләре белән бүләкләү материаллары Министрлыкка бәйрәмгә кадәр өч айдан да соңга калмыйча, ә юбилейлы, истәлекле датага кадәр тиешле дата килеп җитәргә ике айдан да соңга калмыйча тапшырылырга тиеш.

Министрлыкның ведомство бүләкләре белән бүләкләүгә аннан соңгы тәкъдим итүләр алдагы бүләкләүдән соң 2 елдан да иртәрәк башкарыла алмый.

4. Ведомство бүләкләре белән бүләкләү турындагы карар Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры тарафыннан (алга таба – министр) Министрлыкның дәүләт һәм ведомство бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдимнамәләрне карау комиссиясе бәяләмәсе буенча кабул ителә. Бүләк төре Бүләк турында нигезләмәне, бүләкләү өчен тәкъдим ителгән зат казанышларының дәрәҗәсен һәм холкын исәпкә алып билгеләнә.

5. Ведомство бүләкләре белән бүләкләү турында үтенечне түбәндәгеләр белдерергә мөмкин:

министр урынбасарлары, Министрлыкның ведомство буйсынуындагы учреждениеләре җитәкчеләре, җирле үзидарә органнары җитәкчеләре, оешмаларның, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, иҗтимагый берләшмәләрнең җитәкчеләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары җитәкчеләре, югары һәм урта уку йортлары җитәкчеләре.

6. Әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән үтенеч язуы инициаторларының һәркайсысы ведомство бүләге белән бүләкләү турындагы мәсьәләне карау өчен министр исеменә түбәндәге документларны тәкъдим итә:

үтенеч язуы;

әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасына ярашлы рәвештә билгеләнгән форма буенча, бүләкләнүче затның конкрет казанышларын һәм яуланган үрләрен тасвирлап, күрсәтмә.

7. Дисциплинар шелтәсе алынмаган, федераль законда билгеләнгән тәртиптә алынмаган яки үтәлмәгән хөкеме булган затлар ведомство бүләкләре белән бүләкләнергә тиеш түгел.

8. Ведомство бүләкләре белән бүләкләү турында Министрлык боерыкларының күчермәсе, шулай ук ведомство бүләкләре хезмәткәрне бүләкләүгә тәкъдим иткән оешмадан ышаныч кәгазе буенча бирелә.

9. Министрлыкның ведомство бүләге белән бүләкләнгән хезмәткәренең хезмәт кенәгәсенә бүләкләү турында язу теркәлә.

10. Ведомство бүләкләрен тапшыру министр тарафыннан яки аның кушуы буенча тармакны тикшерүдә тотучы министр урынбасары яки министр исеменнән оешманың (учреждениенең, берләшмәнең) башка вазыйфаи затлары тарафыннан тантаналы шартларда башкарыла.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының ведомство бүләкләре белән бүләкләүгә күрсәтмә

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) _______________
______________________________________________________________________________
2. Туган көне, ае, елы_________________________________________________________
3. Туган урыны ______________________________________________________________
4. Белеме ____________________________________________________________________
(нинди уку йортын һәм ничәнче елда тәмамлаган)
5. Гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме __________________________________________
6. Яшәү урыны адресы ________________________________________________________
7. Нинди дәүләт, ведомство бүләкләре белән бүләкләнгән
______________________________________________________________________________
8. Эш урыны, биләгән вазыйфасы ______________________________________________
9. Гомуми эш стажы __________________________________________________________
10. Тармакта эш стажы ________________________________________________________
11. Әлеге коллективта эш стажы _______________________________________________
12. Хезмәт эшчәнлеге (югары уку йортларында һәм урта махсус уку йортларында укуны, хәрби хезмәтне дә кертеп).

| Ай һәм ел | | Оешманы күрсәтеп вазыйфа | Оешма урнашкан урын |
|---|---|---|---|
| керү | китү | | |
| | | | |
| | | | |

<u>1-12 пунктлардагы</u> мәгълүматлар хезмәт кенәгәсе мәгълүматларына туры килергә тиеш.

______________________________________________________________________________
М.У. (кадрлар хезмәте җитәкчесенең Ф.И.А., вазыйфасы, имзасы)

13. Бүләкләүгә тәкъдим ителүче затның конкрет казанышларын күрсәтеп, характеристика:

______________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

Кандидатура

________________________________________________________________________________

(Фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы-булган очракта)

тәкъдим ителде______________________________________________________________

________________________________________________________________________________

(оешма исеме, хезмәткәр коллективының, аның советының яки коллегиясенең җыелу датасы, беркетмә номеры)

Учреждение җитәкчесе

___________________________________

(имза, фамилия, исем, ата исеме (булганда)

М. У.»______»_____________________

Сайланулы һөнәри берлек органы рәисе (хезмәт коллективы советы рәисе)

___________________________________

(имза, фамилия, исем, ата исеме (булганда)

М. У.»______»_____________________ел